**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«СӘМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«24» октября 2022 ел № 24/1

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексының 26 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары (2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 2018 елның 14 июнендәге 481 номерлы, 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы, 2018 елның 29 декаберендәге 1320 номерлы, 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы, 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы, 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), авыл җирлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы «Сәмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 22 маендагы 29/2 номерлы карары белән (2018 елның 08 декабрендәге 34/3 номерлы, 2020 елның 227 маендагы 46/2 номерлы, 2021 елның 29 декабрендәге 18/1 номерлы карарлар үзгәрешләре белән) расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы муниципаль берәмлек Башлыгының, муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарының айлык акчалата түләү күләмен 1,04 тапкырга арттырырга;
- Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады күләмнәрен биләгән муниципаль хезмәт яисә муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә 1,04 тапкыр арттырырга;

1.1. Нигезләмәнең 1 кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә:

Акчалата түләүнең һәм акчалата кызыксындыру түләвенең
иң чик күләмнәре

| Вазыйфа исеме | Акчалата түләү (сумнарда) | Акчалата кызыксындыру түләве (сумнарда) |
|---|---|---|
| Сәмәкәй авыл җирлеге Башлыгы | 16390 | 9179 (6,72%) |

1.2. Нигезләмәнең 2 кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазыйфа исеме | Хезмәткә түләүнең 12 төркеме |
|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 16383 |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | 15905 |
| Әйдәп баручы белгеч | 13274 |
| 1 категорияле белгеч | 11958 |

2. Әлеге карар 2022 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Сәмәкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе И.М. Усманов